| СОВЕТ КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2023 ел Коланҗы т. юл ст № 52

Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советының 2017 елның 5 сентябрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 06 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советының 2017 елның 5 сентябрендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында» нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 статьяның 1 пунктының 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Башлыгына (Раисенә) (алга таба - Рәис) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә белешмәләр тапшыра. Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат депутат булып сайланган көннән алып дүрт ай эчендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра, вакантлы депутат мандатын аңа тапшыра. Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм

аларның керемнәре чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда Россия Федерациясе законнары нигезендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра. Хисап чоры дәвамында «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-биреш башкарылмаган, гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып киткән очракта, җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат бу хакта Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә. Җирлек Советы депутатының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматтан, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрдән, мондый затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Җирлек Советы депутатының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган шәхси мәгълүматлар булмаган очракта, һәм тиешле затка ия булган милекне индивидуаль реализацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар булмаганда) тапшыру бурычының үтәлүе (тиешенчә үтәлмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә Колаңгы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырыла. Җирлек Советы депутатының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4_3 өлеше кагыйдәләре кулланылмый.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Колаңгы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы Ф.Т.Нигматзянов